ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2024 п.г.т.Алексеевское № 207

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 01.07.2011 ел, № 549 «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган җирле бюджеттан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында «14.06.2011 № 477 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 06.05.2024 ел, № 300 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына ярашлы рәвештә

**карар бирәм**:

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган җирле бюджеттан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 01.07.2011 ел, № 549 карарына (Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 02.11.2011 дән № 796, 12.11.2012 дән № 899, 25.10.2013 тән № 836, 24.04.2015 тән №200, 05.11.2015 тән №453, 04.07.2016 дан №283, 24.08.2017 дән №330, 22.02.2018 дән № 41, 02.12.2022 дән № 434, 30.12.2022 дән № 586 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «2018 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2024 елның 1 июленнән» дигән сүзләр белән алыштырырга;

Күрсәтелгән карарның 1 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта).

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Алексеевск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Е.М. Мифтаховага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
29.05.2024 ел, № 207
карарына кушымта

**Җирле бюджеттан финанслана торган бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)**

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 19 242,0 |
| 2 | 1,0126 | 19 484,0 |
| 3 | 1,0256 | 19 735,0 |
| 4 | 1,0381 | 19 975,0 |
| 5 | 1,0521 | 20 245,0 |
| 6 | 1,0656 | 20 504,0 |
| 7 | 1,0802 | 20 785,0 |
| 8 | 1,0942 | 21 055,0 |
| 9 | 1,1083 | 21 326,0 |
| 10 | 1,1233 | 21 615,0 |
| 11 | 1,1379 | 21 895,0 |
| 12 | 1,1535 | 22 196,0 |
| 13 | 1,1691 | 22 496,0 |
| 14 | 1,1846 | 22 794,0 |
| 15 | 1,2008 | 23 106,0 |
| 16 | 1,2174 | 23 425,0 |
| 17 | 1,2340 | 23 745,0 |
| 18 | 1,2512 | 24 076,0 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1- 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.